**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт,
штп. Кама Тамагы, 422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70, e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru, http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2021 № 478

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең аерым административ регламентларының үз көчләрен югалтуын тану турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты ПОСТАНОВЛЯЕТ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең түбәндәге административ регламентлары үз көчләрен югалткан дип таныրга:

- Балигъ яшьтәге хокуктан файдалануга сәләтсез зат мәнфәгатьләрендә опекунга торак хосусыйлаштыруга рөхсәт бирү буенча муниципаль берәмлекләр тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (4 нче кушымта);
- Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче Россия Федерациясе гражданнарына уллыкка алу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты һәм уллыкка алучыларга кандидат буларак исәпкә кую (12 нче кушымта);
- Балигъ булмаганнарның күчмә милкен читләштерү буенча алыш-бирешләр кылуга алдан рөхсәт бирү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты (13 нче кушымта);

- Россия Федерациясе территориясендә даими яшәүче ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга (түләүле яисә түләүсез шартларда) опека (попечительлек) билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты яисә опекун (попечитель) булу мөмкинлеге турында бәяләмә бирү (15 нче кушымта).

2. «Дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын раслау турында» Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 апрелендәге 434 номерлы карарының 1.12, 1.13 һәм 1.15 пунктларын үз көчләрен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (https://kamskoye-ustye.tatarstan.ru) урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В. Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче Р. М. Заһидуллин